# КҮҢЕЛЕМӘ САЛДЫМ ЯКТЫСЫН

Мин Илдус Диндаровны һәм аның ул чакта әле башланып кына килгән иҗатын күптәннән — үткән гасырның 60 нчы елларыннан ук беләм. Ул заманнарда татарда, бәлки, бердәнбер данәдә сакланып калган Диндаров фамилиясен йөрткән, сукса тимер өзәрлек Илдусыбыз Түбән Кама төзелешләрендә эшли һәм шәһәребездә әле яңа гына оешып киткән «Кама таңнары» дигән әдәби берләшмәгә йөри иде. Яшь каланың бураннарга уралган төзелеш мәйданнары, бураннарда якаларын күтәреп берләшмә утырышларына килгән Рахмай Хисмәтуллин, Әхмәт Гадел, Фәннур Сафин, Мисхәт Хәбибуллин, Заһир Сәмигуллин, Мөслах Таҗилар әле һаман да күз алдында тора. Боларның күбесе бакыйлыкка күчкән инде. Урыннары җәннәттә булсын мәрхүмнәрнең...

Менә бит «Диндаров» дигән легендага тиң сирәк фамилия ничек итеп мине истәлекләр чоңгылына бөтереп алды. Юк, барысы да табигый. Шул ук гасырның 90 нчы еллары башында миңа Уфадан Чаллыга күчеп килергә насыйп иткәч, язмыш мине икенче бер талантлы шәхес — Ирек Диндаров дигән курку белмәс, темасын чүкеч белән кадаклый торган радиожурналист һәм үзендә шуның киресен — нечкәдән дә нечкә нәсер остасы булу сәләтен берләштергән зат белән таныштырды. Фаҗигале үлеменнән ике-өч ел алдан без аның белән бик якыннан аралашып яшәдек. Миңа аның беренче нәсерләренә сүз башы язу бәхете тиде. Мин ул чакта: «Бу Диндаровларның барысы да талантлы кеше була, ахрысы», — дип, эчтән көлемсерәп тә куйган идем. Һәм иң кызыгы шул: Ирек Диндаров теге мин белгән Илдус

Диндаровның бертуган энесе булып чыкты бит!.. Соңыннан ишетүемчә, заманында Чирмешән якларында укытучы һәм район гәзите мөхәррире булып эшләгән Гали аганың уллары булгач та, алар ничек сүз гамәле дигән таланттан коры калсын ди инде?!

Менә мин Илдус Диндаров белән тагын да очраштым: ул яшәгән Нурлат шәһәренең үзенә — күренекле язучыбыз Тәлгат Галиуллинның юбилей кичәсенә баргач. Илдусның «Ватаным Татарстан» гәзитенең Нурлат төбәге буенча үз хәбәрчесе булып эшләвен дә белә идем. Бу юлы очрашу иң кыска юл — «Гомер фасыллары» исемле тәүге китабы аша булды. Ләкин тагын да шунысы кызык: үткән заман белән әнә шул дөнья күргән китап арасында юл озын — нәкъ кырык ел килеп чыга. Сүз гамәле шундый могҗизалардан тора шул ул. Аннан соң да Илдус берничә җыентык бастырырга өлгерде.

Менә монысын, нәүбәттәгесен исә, гомер буе «әдип булам» дип хыялланмаган, әмма, хыялланмыйча да, тумышыннан әдип булып яратылып, гомер буе тузанлы гәзит битенә шундый ук тузанлы репортажлар ташыган журналист-публицистның инде үзе дә сизмичә җитлеккән шагыйрь, җитлеккән прозаик, җитлеккән юмор-сатира һәм тирән фәлсәфи парча-уйланулар остасы икәнлеген раслаган хикмәти бер мәҗмуга дип атарга мөмкиндер. Ул лирикага һәм юмор-сатирага бүленгән ике өлештән тора. Аларның «үз кәнфите», талант дигән орлык ярылып яткан ачышлары байтак. Алар хакында, гомумиләштереп, аерым мәкаләләр язып булыр иде. Әмма мин, Илдус кардәшемнең гаять шаян, шук юморын, ачы сатирасын югары бәяләгән хәлдә, үземә аеруча

якын булган лирик шигырьләренә генә тукталырга булдым.

Ихластан да, мәшһүр Бабич әйтмешли, юл саен диярлек «ачыш йолдызлары» бар аның ул иҗат җимешләрендә. Мәсәлән, шигъриятттә күп кулланыла торган гап-гади кош — тургай нәрсә инде ул? Нишли? Илдус шигырендә менә нәрсә һәм менә ни эшли ул тургай: *«Тургай күктә — кояш нурларында Чәбәләнгән төсле күренә.» («Гомер фасыллары»), «Ай аралап керде, хисләнеп; Капшады да сүрән йөзебезне, Читкә алды нурын сискәнеп» («Озату»), «Кыек яуган кояшлы яңгырның Чабып кердек «чабуы» астына» («Кояшлы яңгырдан соң»), «Камырлы куллары әнинең, Чәбәкләп пешергән ипинең Хуш исен сеңдергән кочагы...» («Арышның баш кыскан шау мәле...»)* Һәм башка күп гаҗәеп якты, матур юллар... Экология темасына багышланган үзәк өзгеч сагышлы элегиягә тиң шигыре тагы *(«Шушы сулар сыман гомер уза, диеп»)...*

Һәм, ниһаять, күңелемне тетрәткән «Кояш баткандa»сы. Салкын кырда төнгә калган колынлы ат турында ифрат янә бер моңлы элегия. Моңсу җыр. Байтал үзенең яныннан җилдереп кенә үткән җилбәзәк кырыкмышларга моңсуланып карый. Аксак атның хәле билгеле инде... «*Ул да җиләр иде юләр сыман — Хәле юк шул атларга.* Җитмәсә, *«Дагасы юк, инде тут та төшкән яшь чактагы утлы тоякка».* Яланда чабулаучы колынын күзәткәндә күзләре яшьләнә икән, куанычтан гынамыни бу? «Сабыем» дип иярмәкче итә, әмма, әмма... Һәрнәрсәнең үз вакыты бар: *«Кыш җиткән шул: кәфенләгән төсле Беренче кар яуды болынга...».*

Сез күз алдыгызга китерәсезме: инде печәннәре чабылган, игеннәре урылган, сөреләсе басу-

ларга беренче кар яткан. Беренче кар! Нинди сафлык, аклык!.. Монда гармуннар, мандолиналар, скрипкалар моңы ишетелә башлый. Шигырьдә бу хакта бер сүз дә юк. Әмма сез аны ишетәсез. Алар байталның күкрәгендә бәргәләнә. Менә тагын көн үтә. Яланда кызык та бетте. Кышның кичке салкыны яланнарга гына түгел, газиз баласын – колынын тудырган-үстергән Ана-Байтал белән аның шул йөрәк пәрәсе — колыны арасына да керә. Нишләмәк кирәк, тормыш-язмыш чынбарлыгы, һәм кинәт, скрипканың зеңләп өзелгән кылы кебек, шагыйрь кисәтүе яңгырый:

Атны ташлап колын торып чапты
Печән салган җылы аранга...

Бу шигырь үзебезнең тормыш, балалары ташлап киткән япа-ялгыз аналар язмышы турында да түгелмени?! Моңсу да, ямансу да бит, әйеме? Ә шулай да тормыш матур һәм матур булырга тиеш. Яшәүнең катгыйлыгы һәм кырыслыгы әле аның өметсез булуын расламый. Киресенчә, матур колынлы байталларыбыз исән булсын. Беренче тапкыр яуган карлар аклыгы белән яктырган авылларыбызда, басу-кырларыбызда, җырларыбызда иминлек булсын. Илдус Диндаровның тирән хистойгылар уята белә һәм уйландыра торган халыкчан шигърияте күңелләребезгә әнә шундый яктылык сирпи.

*Айдар Хәлим,*
*Татарстан Язучылар берлегенең*
*Гаяз Исхакый исемендәге бүләге иясе*

## ХӘСӘН ТУФАН СӘГАТЕ

*(Аксубай районының Иске Кармәт авылындагы шагыйрь музеенда)*

Дөньясына исе китми,
Әллә төн дә, әллә көн,
Гел бер көе йөреп тора
Иске өстәл сәгате.

Хуҗасы чыгып киткәнгә
Үтте күпме гомерләр!
Күңелгә тик шулай тоела:
Менә килеп керер дә

Әйтер төсле: «Йә, канәтем,
Илдә нинди хәлләр бар?
Киләчәккә юл еракмы,
Кыскарамы аралар?»

Ничек җавап бирергә дә
Гаҗиз булырмын сыман,
Алдагысын кем дә белми,
Юлларда бүген томан...

Ә сәгать ваемсыз гына,
Һаман шулай акыртын,
Исәпли күк шагыйрь дәверен,
Саный татар вакытын.